РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2026 №1-20

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясендә коммуналь хуҗалык корылмасы системасын реконструкцияләүне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге милкенә түләүсез тапшыру турында

2004елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Федераль закон ( 07.06.2025 ред) һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 13 июнендәге 374 номерлы ( 22.11.2024 ред.) Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясендә коммуналь хуҗалык корылмасы системасын реконструкцияләүне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге милкенә түләүсез тапшырырга (1 нче кушымта нигезендә).
2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә (алга таба – Палата) мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш (https://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Түбән
Наратбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шәрәфетдинов

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл
җирлеге Советы
30.07.2026 елдан 1-20
номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге милкенә тапшырыла торган коммуналь хуҗалык корылмалары турында белешмәләр

| № т/б | Исеме | Кадастр номеры | Урнашкан урыны | Озынлыгы, м. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бикмураз авылы  Яшьләр бистәсендәге 170 йортка торак төзелешнең сууткәргеч челтәрләре | 16:14:000000:1212 | ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Бикмураз авылы | 4120 |
| 2 | Су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләре | 16:14:000000:1193 | ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Бикмураз авылы, Төньяк-Көнчыгыш бис.. | 1407 |
| 3 | Буа муниципаль районы Бикмураз авылының Төньяк-Көнчыгыш бистәсендә 143 торак йортка компактлы торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү. Су белән тәэмин итү | 16:14:000000:1707 | ТР, Буа районы, Бикмураз авылы | 2941 |
| 4 | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бикмураз авылы Яшьләр бистәсендәге 170 йортка торак төзелешнең канализация челтәрләре | 16:14:100203:843 | ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Яшьләр бис. | 7799 |
| 5 | Су белән тәэмин итүнең тышкы | 16:14:100203:835 | ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, | 2605 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | челтәрләре | | Бикмураз авылы, Төньяк-Көнчыгыш бис | |
| 6 | Канализациянең тышкы челтәрләре | 16:14:000000:1195 | ТР, Буа районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Бикмураз авылы, Төньяк-Көнчыгыш бис | 3175 |